РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» март 2021 ел г. Альметьевск № 292

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 01 августындагы 1226 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы закон нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 01 августындагы 1226 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү секторы (Төхбатуллина А.Б.)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының сәүдә, кулланучылар хезмәтләре күрсәтү һәм эшкуарлык үсеше бүлеге (Хәбибуллин Д.Р.) сүзләренә алмаштырырга»;

карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Аклар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү акт проекты әзерли торган акт проектында әзерләнгән нигезләмәләрнең җайга салу йогынтысы дәрәҗәсен исәпкә алып уздырыла:

1) җайга салу йогынтысының югары дәрәҗәсе - акт проектында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә элек законнарда каралмаган бурычларны, физик һәм юридик затлар өчен тыюларны һәм чикләүләрне яисә аларны билгеләүгә этәрүче нигезләмәләр, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар чыгымнары законнарында элек каралмаган барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләр бар;

2) җайга салу йогынтысының уртача дәрәҗәсен - акт проектында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар өчен законнарда элек каралган бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә физик һәм юридик затлар чыгымнарын арттыруга китерә торган нигезләмәләр бар;

3) җайга салу йогынтысының түбән дәрәҗәсе - акт проектында әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында каралган нигезләмәләр юк, әмма әлеге нигезләмә нигезендә җайга салу йогынтысын бәяләү булырга тиеш».

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 1.3.1 пункт өстәргә:

«1.3.1. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү гамәлгә ашырылмый:

1) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектлары;

3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорга табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.».

1 бүлекнең 1.6 пунктындагы дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

8 бүлекнең 8.2 пунктында «10 эш көне дәвамында» сүзләрен «Өч эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ